яшь хәбәрче мәктәбе

Хөрмәтле укучыларыбыз! Газетабызның узган саннарында "Альметьевский вестник" редакциясе каршысында кабаттан "Школа молодого журналиста"-"Яшь хәбәрче мәктәбе" эшли башлавын хәбәр иткән идек инде. Каләм тибрәтүче яшьләребез белән берничә тапкыр очрашулар да уздырдык. Бүген сезнең игътибарга мәктәптә шөгыльләнүчеләрнең язмаларын тәкъдим итәбез. Талантлы балаларның кызыклы язмаларын көтеп калабыз.

Габдрахман - безнең авыл, шуңа сокландыра ул

Һәркем дә бу дөньяда йөрәгенә якын, җанына җылылык бирә торган яраткан урында гомер итәргә хаклы. Безнең өчен дә иң кадерле, беренче тапкыр дөньяга аваз салган, Әлмәт шәһәренең капкасы булган Габдрахман авылы. Шагыйрә дә бит:

Габдрахман-матур авыл,
Безнең авыл була ул.
Таулары бар, урман якын,
Шуңа сокландыра ул,- дип йөрәгенең түреннән кайнап чыккан чишмә кебек иң җылы сүзләрен шигъри юлларга салган.

Авылыбызның тарихы бик бай. Бүгенге көннәргә кадәр сакланган истәлекләр түбәндәгеләрне сөйли...

"Габдрахман белән Җомагол Тайсуган юлына борылып, Зәйдәге басма-күперне чыгып, авылның мәчет урамы буенча мәдрәсә яныннан кайтып килгәндә, кояшка баю кызыллыгы кергән иде. Озак көттермәде Габдрахман: үзенең бөтен уй-фикерләрен аңлатып, әтисен чакырып хат язды. Бикмөхәммәт мулла да бик тәвәккәл иде, озакламый җыенып, килеп тә җитте. Улы Габдрахман белән бергәләп, Чишмәле аланын карап чыкты, урын бик ошады: инеш һәм чишмәләр дә бар, почта юлы да якын иде.

- Аллаһы боерса, киләсе елдан башлыйбыз,-диде Бикмөхәммәт, бик яхшы урын, ходай насыйп итсә, күршеләрең дә күп булыр, синең дә бит мәдрәсәдә ахыргы елың, күршеләреңдә үк мулла булырсың, амин. Бикмөхәммәт зур теләкләр белән дога кылды.

Шулай итеп, Габдрахман авылына нигез салынды.

1728 нче елда иң беренче булып авылга аяк басучы Габдрахман бине Бикмөхәммәт була. Ул шунда гаилә кора, аның биш бала үстерә. Тимерҗан, Исмәгыйль, Гали, Габдрәхим, Ибраһим. Барысы да бергәләп шунда яши башлыйлар. Почта юлы буйлап Идел-Чулман якларыннан Агыйдел -Урал якларына узучы качак гаиләләр дә шушы урында төпләнеп калалар, йортлар салалар, каралты-кура торгызып, мал карау, җир эшкәртү, умартачылык, сатучылык белән шөгыльләнәләр.

Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чәчкәнен,
Нинди уйлар,нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен,-дигән шигъри юлларын Равил Фәйзуллин нәкъ безнең Габдрахман авылы тарихына багышлагандыр.

Әйе, вакыт уза тора, авыл үсә, ныгый, мәчетләр салына, кибетләр ачыла, мәктәп төзелә, юллар киңәйтелә.

1913 нче елдагы зур янгын җыелган мал-мөлкәтне, төзелгән йортларны бик тиз арада ялмап алып көл итә, авыл өстендә утырып калган морҗа-мичләрнең ялгыз торбалары гына бу урында гөрләп торган авыл булганлыгын искәртә. Әле ярый Зәй елгасы буендагы мәчетне ялкыннан саклап кала алалар.Авылның тырыш халкы яңадан шушы аланда авылны торгыза, көзгә һәр гаилә үзенә кыш чыгарлык итеп куыш булдыра.

Авылыбызның танылган шагыйрәсе, 200 дән артык шигырьләр китабы авторы Энҗе апа Мөэминованың шигырендәгечә:

Һәр тәрәзә миңа нидер сөйли
Таныш һәрбер капка тавышы,
Каршы чыга миңа һәрбер өйдән
Кабатланмас кеше язмышы.

Һәр төбәкнең горурлыгы - аның кешеләре. Габдрахман авылы талантлы шәхесләргә бай авыл: шагыйрә Энҗе Мөэминова, танылган язучы Афзал Таһиров, укытучы, композитор һәм башкаручы Розалия Гәлләмова, шагыйрә Гүзәлия Галләмова һәм башкалар.

Төбәгебезнең мөхтәрәм шәхесләре арасында "Татнефть" ачык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шәфәгать Фахразый улы Тәхәветдинов аерым урын алып тора.

Шәфәгать абый Габдрахманда туып үсә, авыл мәктәбендә белем ала, зур оешманың җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелгән олы йөрәкле, игелекле кешеләрнең берсе. Нәкъ менә аның ярдәме һәм нефтьчеләребез булышлыгы белән авыл һаман зурая, яңара, төзеклән҃ә. Габдрахман, чын мәгънәсендә, Әлмәт районының капкасы.

Без, бүгенге буын балалары - үзебезнең туган авылыбызны яратабыз, аның белән чиксез горурланабыз, киләчәк тормышыбызны туган авылыбызның дәвамчылары итеп күзаллыйбыз.

Зәкиева Диана, Исмәгыйлева Альмира, 8 нче сыйныф укучылары

Карак

(Хикәя)

Барлыкка килгән проблемалар аркасында Фәниягә вакытлыча тулай торакта яшәргә туры килде. Андый урындагы тәртипне белмәгән кеше юктыр инде. Юыну бүлмәләре, кухняише уртак бүлмәләрдә еш кына бик уңайсыз була. Коридорда уйнап, чабып йөргән балаларның чыр-чу килүләре, яшьләр яшәгән бүлмәләрдән килгән көчле музыка тавышы- болар барысы да эштән арып кайткан кешегә рәтләп ял итәргә бирми. Фәния дә шундый атмосферада торырга мәҗбүр. Боларга гына түзеп булыр иде кебек, ләкин соңгы вакытларда Фәния яшәгән катта әйберләр югала башлады. Әле бер күршесе элгән керенең юкка чыгуыннан зарлана, әле икенчесе савыт-сабасының югалганын әйтә. Сагалап та карадылар, ләкин әйберләр югала торды, ә карак һаман табылмады. Тора-бара кешеләрнең бер-берсенә ышанычлары югала барды. Коридорда очрашкан саен, бер-берсе белән коры гына исәнләшеп, тизрәк китү ягын карадылар. Ләкин Фәниянең алай югалган әйберсе булмады һәм ул шуның өчен бик үк борчылмады да.

Тыныч кына чәй эчеп утырган чагы иде. Кинәт кемдер каты гына ишек какты һәм:"Фәния, бер генә минутка чык әле",- диде.Фәния ишекне ачкач аптырап калды. Анда ул яшәгән катның барлык хатын-кызлары диярлек җыелган иде.

-Берәр нәрсә булдымы әллә?- диде Фәния.

Гөлсинә болай дип сүзен башлады:

-Фәния, син күчеп килгәннән бирле безнең әйберләр юкка чыга башлады. Ләкин синеке генә югалмавы безгә бик сәер тоелды.

Шул арада, Гөлсинәнең сүзен бүләбүлә, Нәҗия чәчрәп:

- Тагын бу хәл кабатланса, без комендантка шикаять язып, сине бүлмәдән чыгаруларына ирешәчәкбез,- диде.

Күпмедер вакыт Фәния гарьләнүеннән сүз таба алмыйча торды. Аңа, кеше әйберсен түгел, урамда тапканын да алмаган кешегә, бер сәбәпсез карак исемен тагып куйдылар. Аның әйтә алган барлык сүзе шул булды:"Гомеремдә дә кеше әйберсенә тигәнем булмады һәм тимәячәкмен дә!"

Ул бүлмәсенә кереп ишеген шапылдатып япты һәм караватка йөзтүбән ятып бик озак елады. Әлбәттә, бу көннән башлап Фәния белән күршеләр арасында аралар өзелде. Барыннан да бигрәк Фәниягә Нәҗия бәйләнде, күргән саен берәр агулы сүз әйтеп Фәнияне рәнҗетергә тырышты.

...Бу хәлләрдән соң берничә ел үтте инде. Фәния уңышлы гына кияүгә чыгып моннан күчеп китте һәм тыныч кына үз тормышы белән яши башлады. Тулай торакта аның бур булмаганына күптән ышанганнар иде инде, чөнки әйбер югалулар Фәния киткәннән соң да туктамады.Ә Нәҗиянең үз-үзен тотышы шулхәтле ышанычлы булды, әйберләрне урлаучы кеше Нәҗия дип, беркем уйлап та карамады.

Әйе, Фәниягә яла ягучы да, чит кешенең әйберләренә кызыгучы да Нәҗия иде. Моның турында белмәсәләр дә, карак җәзасыз калмады. Әллә Фәниянең рәнҗеше төшкән, әллә Алла җәзасын биргән, Нәҗия гаилә һәм балалар бәхетен татымыйча, гомерен ялгызлыкта үткәрде.

Соңгы сулышын алганда да янында якын кешеләре булмауга ул бары тик үзе генә гаепле иде...

Эльвира САФИУЛЛИНА, Р.Фәхреддин исемендәге 1 нче гимназия укучысы

Театр яктылыкка, нурга илтә

Узган уку елы ахырында республикабызның мәктәп, лицейларында эшләп килүче театр коллективлары Яр Чаллы шәһәренә чираттагы "Сәхнә көзгесе" милли балалар театры фестивале барган иде. 2006-2007 нче уку елыннан башлап, әлеге милли балалар театры фестивале республикабызда танылу алган бердәм коллектив. Аның белән беренче категорияле педагог Нәфидә Хәкимова җитәкчелек итә. "Нур" бүлеген яшь белгеч Рөстәм Фәттахов җитәкли. Алар безне, ерак юлдан килгән коллективларны, һәрвакыт якты һәм җылы йөзләре белән каршылап, алдагы чыгышыбызга зур этәргеч биреп, рухландырып торалар.

Фестивальдә барлыгы 59 коллектив катнашты. Оештыручылар фикеренчә, киләчәктә катнашучылар төркеме тагы да артачак. Димәк, фестивальнең яшь буынга тәрбия бирүдә кыйммәтле чыганак булу дәрәҗәсе көннән-көн үсә. Әлеге матур башлангычны дәвам итеп, 1 нче лицей-интернатының 9"Б" сыйныфы укучылары белән көчебезне сынап карарга булдык. Сәхнәләштерү өчен Илтөзәр Мөхәммәтгалиевнең кешеләрне гүзәл киләчәккә рухландыручы "Хикмәтле чүлмәк" әкиятеннән өзек сайлап алынды. Әлеге спектакльнең төп геройлары 9"Б" сыйныфы укучылары: Роберт Гыйләҗев (Котсызҗан), Рәсим Шәрифҗанов (Шыксызҗан), Илнар Сибгатуллин (Шайтан бабай), Наил Гыйләҗетдинов (Миңлехәсрәт), Римас Сабиров (Нурлыҗафа), Мөхәммәт Хәлирахманов (Габдулла) булдылар.

Сәхнәләштерелгән әкият бер сулышта узып китте. Халык авыз иҗаты әсәрләрен, гадәттә, балалар яратып укыйлар, аларны чын күңелдән, гаять көчле хисләр, тойгылар аша кабул иттеләр. Кешенең хыялларын чагылдыру, аларда гыйлем алу кебек күркәм сыйфатлар турында сөйләү; тискәре сыйфатлар: алдашу, арттан килеп һөҗүм итү, рәнҗетүне тәнкыйть итү белән безне үзенә тартты. Нәкъ шушы сыйфатлар бүгенге буын укучысына тәэсир итә дә инде. Бу үзенчәлектән тәрбия максатында киң һәм нәтиҗәле файдалану сорала.

Мәртәбәле жюри 5 төп бәяләү критериясен (режиссерлык хезмәте; актерлык осталыгы; музыкаль һәм сәнгатьчә бизәлеше яшь үзенчәлекләренә репертуарның туры килүе; сәхнәдә куелышта иҗади табышлар) күздә тотып, 59 коллектив арасыннан безнең коллективның чыгышын иң югары дип билгеләде, гран-прига лаек дип тапты.

Яңа уку елында да 1 нче лицей-интернатың драма түгәрәге актив эш чәнлеген дәвам итә. Быел да без яшь тамашачыларыбызны кызыклы һәм мавыктыргыч спектакльләр белән сөендерербез, дип уйлыйм.

Зөлфия ИСМӘГЫЙЛЕВА, 1 нче лицей-интернат драма театры түгәрәге җитәкчесе

Что такое счастье?

Счастье - это очень короткий миг. Раз и случилось. И со временем она куда-то исчезает, не проходит и минуты. И жизнь идет дальше. Но я считаю, что это нормально. Если бы она не была такой короткой, никто бы к ней так не стремился. Не нужно искать счастье. Счастье всегда находится у тебя внутри.

Да, действительно у каждого есть свое понятие счастья. Для кого-то счастье-это крутые машины, Рим и Куба, куча шмоток и развлечения. А для кого-то счастье-это просто уютный домик, иметь семью. Сидеть на кухне и пить чай с вареньем. Все зависит от человека. От его понятий. Я считаю, что не бывает злых и добрых людей. Бывают только счастливые и не очень. Если бы люди меньше злились, они видели бы много прекрасного. К сожалению многие забывают, что в мире есть доброта. Они повсюду ищут зло и плохое. Я считаю, что нужно заниматься и делать то, что делает тебя счастливым. Нужно жить, пока живы и, наслаждаться каждой секундой прожитой в этом мире, воспринимать все с лучшей стороны, забывать плохое, тогда счастье зачастит к вам приходить. И жизнь изменится в лучшую сторону.

Прежде всего, чтобы стать счастливым человеком, нужно дарить добро другим людям. Помогать бедным, инвалидам, бездомным животным и больным детям. Ведь они тоже хотят быть счастливыми, хотят также ходить, улыбаться, бегать, наслаждаться жизнью, а не страдать от голода и холода. Некоторые люди, имея теплый дом, здоровье, родителей, показывают недовольство к жизни. Нужно ценить то, что имеешь. И дарить счастье окружающим, делать добро. Порой, люди всю жизнь гонятся за счастьем, не понимая, что счастье и есть жизнь. Наслаждаться жизнью это и есть счастье. И я верю, что это самое главное на свете.

Камиля ИСМАГИЛОВА, ученица 9 б класса гимназии №1 им. Р.Фахреддина

С 2014 года снижаются страховые взносы для самозанятого населения

Начиная с 2014 года снижается ставка страховых взносов для плательщиков страховых взносов из числа самозанятого населения (индивидуальные предприниматели, адвокаты, нотариусы, главы крестьянских (фермерских) хозяйств и другие физические лица, уплачивающие страховые взносы в фиксированном размере).

С 2014 года размер страховых взносов на обязательное пенсионное страхование для самозанятого населения, чья величина дохода за расчетный период не превышает 300 тыс. рублей, будет рассчитываться исходя не из двух, а одного минимального размера оплаты труда (МРОТ).

Для тех, чья величина дохода превышает 300 тыс. рублей, размер страхового взноса будет исчисляться исходя из одного МРОТ плюс 1% от суммы превышения величины фактически полученного предпринимателем величины дохода за расчетный период. При этом сумма страховых взносов не может быть более размера, определяемого как произведение восьмикратного минимального размера оплаты труда, установленного федеральным законом на начало финансового года, за который уплачиваются страховые взносы, и тарифа страховых взносов в Пенсионный фонд Российской Федерации, установленного пунктом 1 части 2 статьи 12 Федерального закона от 24.07.2009 года № 212-ФЗ, увеличенное в 12 раз.

Также внесены изменения и в сроки уплаты страховых взносов самозанятым населением.

Страховые взносы на обязательное пенсионное страхование в фиксированном размере уплачиваются самозанятым населением до 31 декабря расчетного периода, начиная с 01.01.2014 года независимо от дохода.

Если у плательщика страховых взносов из числа самозянятого населения величина дохода за расчетный период свыше 300 тыс. рублей, то 1% от суммы превышения величины фактически полученного предпринимателем величины дохода за расчетный период, он обязан уплатить в срок до 1 апреля года, следующего за отчетным.

При этом представители самозанятого населения (за исключением глав крестьянских (фермерских) хозяйств) по-прежнему будут освобождены от представления отчетности в Пенсионный фонд.

Сумма обязательных платежей в систему обязательного пенсионного страхования для самозанятого населения в 2013 году рассчитывается исходя из двух МРОТ.

Таким образом, сумма страховых взносов к уплате для самозанятого населения за 2013 год составляет:

- на обязательное пенсионное страхование 5 205 рублей х 2 х 26% х 12 = 32 479,2 рубля в год, или 2 706,6 рубль в месяц;
- на обязательное медицинское страхование 5 205 рублей х 5,1% х 12 = 3 185,46 рубля в год, или 265,46 рубля в месяц.

"Во избежание недоимки и взыскания по страховым взносам самозанятому населению необходимо уплатить страховые взносы за 2013 год до 31.12.2013. На сегодняшней день в республике к такой категории относятся 93 675 страхователей", - отметил управляющий отделением ПФР по РТ Марсель Имамов.

Федеральный закон от 23 июля 2013 г. №237-ФЗ "О внесении изменений в статью 22 Федерального закона "Об обязательном пенсионном страховании в Российской Федерации" и статьи 14 и 16 Федерального закона "О страховых взносах в Пенсионный фонд Российской Федерации, Фонд социального страхования Российской Федерации, Федеральный фонд обязательного медицинского страхования".

Палата земельных и имущественных отношений Альметьевского муниципального района Республики Татарстан согласно Земельному кодексу Российской Федерации сообщает о наличии земельного участка площадью 400 кв.м, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Альметьевск, ул. Габделжаббара Кандалыя, д. 37, предоставляемого в аренду для индивидуального жилищного строительства.

Прием заявлений о предоставлении земельного участка осуществляется в течении месяца с момента опубликования сообщения по адресу: РТ, г. Альметьевск, пр. Тукая, д. 9 "А", 2 этаж, канцелярия, 5 окно, приемные часы: с понедельника по четверг с 8.00 до 17.15 ч., в пятницу с 8.00 до 12.00 ч., обед с 12.00 до 13.15 ч., тел. 43-86-91.

Палата земельных и имущественных отношений Альметьевского муниципального района Республики Татарстан согласно Земельному кодексу Российской Федерации сообщает о наличии земельного участка площадью 401 кв.м, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Альметьевск, ул. Габделжаббара Кандалыя, д. 39, предоставляемого в аренду для индивидуального жилищного строительства.

Прием заявлений о предоставлении земельного участка осуществляется в течении месяца с момента опубликования сообщения по адресу: РТ, г. Альметьевск, пр. Тукая, д. 9 "А", 2 этаж, канцелярия, 5 окно, приемные часы: с понедельника по четверг с 8.00 до 17.15 ч., в пятницу с 8.00 до 12.00 ч., обед с 12.00 до 13.15 ч., тел. 43-86-91.